Роза ХӘМИДУЛЛИНА



# Алмалы чак

## Мин бер Чаллы баласы

Чулман ярлары бизәге –
Гүзәл Чаллы каласы,
Мул суларын иңләп үсәм,
Мин шул төбәк баласы.

Сөендереп, биек йортлар
Калкып чыга һәр елны.
Гөрли калам, үсә Чаллым,
Уң булсын барыр юлы.

Чаллы – батырлар үзәге:
КамАЗлары дан тота.
Уңган-булган егет-кызы
Барыр юлын яктырта.

Олы балачак сукмагым:
Авыл-шәһәр арасы.
Миңа әле үсеп җитеп,
Зур-зур йортлар саласы.

Яз җитүгә ак шәһәрем
Ямь-яшелдән киенә.
Уйнап-көлеп, җырлап-биеп,
Үсәм Чаллы көенә.





ЛКМ-36-80